**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

---

**2022 елның « 17 » гыйнвары** **52номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә яңа урамнарга исем бирү турында**

«Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында» карары белән, Лаеш шәһәрендә 2022 елның 28 октябрендәге, 2022 елның 30 декабрендәге яңа урамнарга исем бирү мәсьәләсе буенча топонимик район комиссиясе утырышы нәтиҗәләре буенча Лаеш шәһәре Советы карар чыгарды.:

1. Лаеш шәһәрендә барлыкка килгән яңа урамнарга түбәндәге исемнәр бирергә:

2. Улица Александра Савельева - Александр Савельев урамы ;
3. Улица Загородная - урамы;
4. Улица Рассветная - урамы;
5. Улица Юности – урамы;
6. Улица Красивая - урамы

(1 кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Арефьевка йөкләргә.

**Башлык - Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районының**
**Лаеш шәһәре Советы рәисе** **И.Ф.Зарипов**